**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Татар Аксуы авылында гражданнар җыены карары**

10.11.2025 № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Татар Аксуы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Югары Лашчы авыл җирлегенең Татар Аксуы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- төзекләндерү, киртәләр кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (зиратка юл салу);
- Татар Аксуы авылында торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Җыен нәтиҗәләрен Югары Лашчы авыл җирлегенең Татар Аксуы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгы __________ Г.Х. Усманова

Халык җыены секретаре __________ Г.Р.Галеева